| | |
|---|---|
| СОВЕТ РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 22ноябре Рус Әҗиле ав. **№183**

Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында»гы 2019 елның 1 ноябрендәге159 номерлы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 12.11.2020 №9 һәм 16.10.2023 №134 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон (2024 елның 29 октябрендәге редакциядә), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында»гы 2019 елның 1 ноябрендәге 159 номерлы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карарына (Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 12.11.2020 №9, һәм 16.10.2023 № 134 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1) 0,2% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, моңа индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләренең һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләренә карата»;

1.2. 1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2) 0,3% шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм аерым Россия Федерациясе актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3%», әлеге

абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссия рәисенә йөкләргә.

**Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **Г.Ф.Семахина**